**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Аксубай
муниципаль районы
муниципаль беремлеге
423067 Иске Кармәт авылы
Ленин урамы, 37
тел. 884344 4-60-38

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Аксубаевский
муниципальный район
муниципальное образование
423067 с. Старая Киреметь
улица Ленина, 37
Тел.884344 4-60-38

**Иске Кармәт авыл җирлеге Советы**

## КАРАР

**№ 29** **23.06.2021 ел**

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне» яңа редакциядә раслау хакында» 19.12.2018 ел, № 78 карарына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив-хокукый актларны законнарга туры китерү максатыннан Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне» яңа редакциядә раслау хакында» 19.12.2018 ел, №78 карарына үзгәрешләр кертергә.

2. 34 бүлекнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнар төзелеше белән билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру».

19.3 пунктының 4 пунктчасы:

«хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яки) законнар төзелеше белән билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләрен өстәргә»;

19.3 пунктының 6 пунктчасы:

«мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы» сүзләрен «индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ" сүзләренә алмаштырырга».

16.1 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) коммерциячел яки коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) түләүсез нигездә сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләре съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу;

б) эшкә алучының Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә алынган вәкиленең рөхсәте белән коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашудан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләре съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш)

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен кайгырту;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманың гамәлгә куючысы вәкаләтләрен башкару тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актларга таянып, муниципаль берәмлек гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен кайгырту;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;»;

32 пунктның 32.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дисциплинар җәзаларны куллану һәм бетерү тәртибе, әлеге Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.»;

18 статьяның 18.14 пункты:

«җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты» сүзләреннән соң «күрсәтелгән затларга карата башка җаваплылык чараларын куллану турында» сүзләрен өстәргә.»;

28.6 пунктын:

«ә стаж озынлыгы һәм айлык түләүләр әлеге нигезләмә нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен билгеләгәндә муниципаль хезмәткәргә билгеләнгән шундый ук мәгънәдә исәпкә алына» сүзләрен «ә сыйныф чины өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын билгеләүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актында билгеләнгән мәгънәдә исәпкә алына» сүзләренә алмаштырырга.

16.1 пунктының 2 пунктчасы:

«бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Үз көчен югалткан дип танырга:

- «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне» яңа редакциядә раслау

хакында» 19.122018 ел, № 78 карарына үзгәрешләр кертү турында» 03.06.2021 ел, № 25 карары».

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://Aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Кармәт авыл җирлеге
Советы Рәисе В.Г.Парфенов